**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет Пестречинского муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» июль, 2020 ел № 1017

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 10 июнендәге 874 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2020 елның 08 апрелендәге 496, 2020 елның 27 февралендәге 308 номерлы үзгәрешләре белән)

«Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 10 июнендәге 874 номерлы карарын (2020 елның 8 апрелендәге 496 номерлы, 2020 елның 27 февралендәге 308 номерлы үзгәрешләре белән) Россия Федерациясе Граждан кодексына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2020 елның 07 июлендәге 01-51/4582 номерлы мөрәҗәгатен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Карарның 1.1. пункты муниципаль учреждениеләргә, муниципаль казна предприятиеләренә оператив идарә итү хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында муниципаль милекне рәсмиләштерү (беркетү) буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (1 нче кушымта) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында http://www.pestreci.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://www.pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе И.Р. Дәүләтхановка йөкләргә.

Район башкарма комитеты җитәкчесе А. В. Хәбибуллин